**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ XXXII СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 132**

Мөслим авылы «20» февраль 2019 ел

**«2019-2021 елларга Мөслим муниципаль районының экологик иминлеге» муниципаль максатчан экология программасын карау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Мөслим муниципаль районында экологик хәлне яхшырту максатларында, Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы И.Х. Әхмәтовның чыгышын игътибарга алырга.
2. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына «2019-2021нче елларга Мөслим муниципаль районының экологик иминлеге» муниципаль максатчан экологик программасын расларга тәкъдим итәргә.
3. Мөслим муниципаль районының финанс-бюджет палатасына ел саен, муниципаль район бюджетын чираттагы финанс елына формалаштырганда, мөмкинлекләрне исәпкә алып, программа чараларын гамәлгә ашыруга акчалар кертүне тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мөслим муниципаль районы Советының авыл хуҗалыгы, төзелеш, сәнәгать, экология һәм җирдән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин